РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адресы: 422870, РТ, БазарлыМатакавылы, Крайновур., 56
тел: тел: 8 (84346) 2-17-60

Адрес: 422870, РТ, с.Базарные Матаки, ул. Крайнова, 56
факс: 8 (84346) 2-17-60


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Базарлы Матак авылы **КАРАР**

2021елның 26 октябре 454№

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 5 февралендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 24 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

2021 елның 2 июлендәге «Россия Федерациясе Гаилә кодексының 54 статьясына һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 36 һәм 67 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 310-ФЗ номерлы Федераль закон, 2021 елның 30 апрелендәге «Россия Федерациясендә физик тәрбия һәм спорт турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2021 127-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы муниципаль мәгариф оешмаларында төп гомуми белем бирү программалары буенча һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүне оештыру турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кушымтаның 2.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бала бертуганнары һәм атасы яки анасы башка булган абыйсы һәм (яисә) апасы белем ала торган дәүләт яисә муниципаль белем бирү оешмасына мәктәпкәчә белем бирүнең һәм башлангыч гомуми белем

бирүнең төп гомуми белем бирү программалары буенча белем алырга өстенлекле кабул ителү хокукына ия.».

2.Әлеге карарны Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В. Юсупов